| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ ГОРОДА ЗАИНСКА<br>ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН<br>ул. Орджоникидзе, д. 49, г.Заинск, 423522 | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ЗӘЙ ШӘҺӘР СОВЕТЫ<br>Орджоникидзе ур.,49 йорт, Зәй шәһәре,423522 |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

03.03.2021 г. Заинск № 32

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә, физик һәм юридик затларның хосусый милкендәге җирләргә кермәгән яшел үсентеләрне (утыртмаларны) кисү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында»**

Россия Федерациясе Урман кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, Россия Федерациясе Торак кодексына, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2011 елның 23 ноябрендәге 961 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына, Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре Уставына таянып, Зәй муниципаль районының Зәй шәһәр Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә, физик һәм юридик затларның хосусый милкендәге җирләргә кермәгән яшел үсентеләрне (утыртмаларны) кисү тәртибе турында нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Зәй муниципаль районының http://zainsk.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Карар басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны экология, җир мәсьәләләре, төзелеш, ТКХ һәм транспорт буенча даими комиссиягә йөкләргә.

**Зәй шәһәре Советы**
**Рәисе** **Р.Г. Кәримов**

Зәй муниципаль районы
Зәй шәһәре Советының
2021 елның 03 03
24 номерлы карарына
кушымта.

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә, физик һәм юридик затларның хосусый милкендәге җирләргә кермәгән яшел үсентеләрне (утыртмаларны) кисү тәртибе турында**

**НИГЕЗЛӘМӘ**

Әлеге нигезләмә Россия Федерациясе Конституциясенә, Россия Федерациясе Граждан кодексының 15 статьясына, Россия Федерациясе Урман кодексына, "Әйләнә-тирә мохитне саклау турында" 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль законның 61, 68, 77 статьяларына, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына нигезләнеп эшләнгән, ул Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә, физик һәм юридик затларның хосусый милкендәге җирләргә кермәгән яшел үсентеләрне (утыртмаларны) кисү тәртибен билгели.

## 1. Төп төшенчәләр

Әлеге нигезләмәдә түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

Яшел үсентеләр (утыртмалар) - агач, куак һәм үлән үсә торган табигый һәм ясалма яшеллек (шул исәптән парклар, скверлар, бакчалар, газоннар, чәчәклекләр, шулай ук аерым торучы агачлар һәм куаклар).

Табигый территорияләр - бердәм географик (климатик) шартларда формалашкан җир рельефының, туфракның, үсемлекләрнең билгеле бер төрләрен үз эченә алган хуҗалык эшчәнлегенә файдаланылмаган яисә аз файдаланылган территорияләр.

Яшелләндерелгән территорияләр - табигый барлыкка килгән үсемлекләр биләмәләре, ясалма барлыкка китерелгән яшел объектлар (авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән тыш), төрле функциональ билгеләнештәге җирләрнең 50 проценттан да ким булмаган өлеше яшеллек белән капланган аз төзелешле кишәрлекләр.

Урман территорияләре - төрле функциональ билгеләнештәге табигый территорияләр участоклары, алар табигый барлыкка килгән урман үсемлекләре белән капланган.

Агач - биеклеге 1,3 метрлы диаметры 5 сантиметрдан да ким булмаган ачык беленеп торган кәүсәле үсемлек, үсентеләрдән кала.

Куак - туфрак яныннан ук тармакланган күпьеллык (агачтан аермалы буларак) үсемлек.

Үлән капламасы - газон, табигый үлән.

Куаклык - нинди дә булса урында куе булып үскән үсемлекләр, куаклар.

Яшел массив – бердәм каплама барлыкка китерүче 50 данәдән дә ким булмаган агач (15 елдан да арткан) үсә торган территория кишәрлеге.

Яшел үсентеләргә (утыртмаларга) зыян китерү – яшел үсентеләргә үсешен туктатуга китерми торган зыян китерү, шул исәптән ботакларга, тамыр системасына механик зыян китерү, кайрының бөтенлеген, тере туфрак катламын бозу, яшел үсентеләрне яисә тамыр зонасындагы туфракны зарарлы матдәләр белән пычрату, ут төртү яки башка төрле йогынты ясау.

Яшел утыртмаларны юкка чыгару (югалту) - яшел утыртмаларны кисү яки аларның үсешен туктатуга китергән башка төрле зыян салу.

Компенсация рәвешендә яшелләндерү – юк ителгән яисә зыян китерелгән яшел утыртмаларны 2 коэффициенты белән яңадан торгызу.

## 2. Яшел утыртмаларны саклауның төп принциплары

Зәй муниципаль районыныж Зәй шәһәре территориясендә үсә торган яшел үсентеләр саклагыч, рекреацион, эстетик функцияләр башкаралар һәм алар сакланырга тиеш.

2.1. Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре территориясендә урнашкан барлык яшел утыртмалар (агачлар, куаклар) якланырга тиеш.

2.2. Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре территориясендә яшел утыртмалар сакланышын һәм үсеш шартларын тәэмин итү бурычлары түбәндәгеләргә йөкләнә:

2.2.1. оешмаларга үзләре белдергән эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру өчен бирелгән кишәрлекләрдә - әлеге оешмаларның җитәкчеләренә;

2.2.2. милектә булган яки арендага алынган кишәрлекләрдә – юридик затларга, гражданнарга-милекчеләргә яки арендаторларга.

2.3. Яшел утыртмалар урнашкан җир кишәрлекләренең милекчеләре, файдаланучылар һәм арендаторлар яшел утыртмаларның сакланышын, яшел утыртмаларны тиешенчә карауны тәэмин итәргә тиеш.

2.4. Элеге нигезләмә Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре территориясендә агач-куак үсемлекләрен кисүгә бәйле проектлау, төзү, ремонтлау һәм башка эшләр алып баручы барлык гражданнарга һәм, милек формаларына бәйсез рәвештә, оешмаларга кагыла.

2.5. Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре территориясендә хуҗалык алып бару, шәһәр төзелеше һәм башка эшчәнлек Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы һәм әлеге нигезләмәдә билгеләнгән яшел утыртмаларны саклау таләпләрен үтәп гамәлгә ашырыла.

2.6. Җир кишәрлеген сайлау акты, төзелеш, хуҗалык һәм башка эшчәнлекне оештыруга проект алды һәм проект документациясендә яшел

утыртмаларның торышы турында тулы һәм дөрес белешмәләр һәм проектлана торган объектның яшел утыртмаларга йогынтысына тулысынча бәяләмә булырга тиеш.

2.7. Яшелләндерелгән территорияләрдән һәм яшел массивлардан яшел утыртмаларның үсүен һәм бөтенлеген тәэмин итми торган файдалану рөхсәт ителми.

## 3. Яшел утыртмаларны (агачларны, куакларны) кисү тәртибе

3.1. Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре территориясендә яшел үсентеләрне рөхсәтсез кисү тыела.

3.2. Зәй муниципаль районы территориясендә агачларны һәм куакларны кисү рөхсәт нигезендә башкарыла. Кисүгә рөхсәт Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе күрсәтмәсе рәвешендә рәсмиләштерелә.

3.3. Яшел үсентеләр кисүгә рөхсәт алу өчен мөрәҗәгать итүче Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе исеменә тиешле форма буенча гариза бирә (1 нче кушымта), анда утыртмаларның саны, атамасы, аларның торышы, чикләнгән кисү урыны һәм аны нигезләү күрсәтелергә тиеш. Гаризага түбәндәге документлар теркәлә:

3.3.1. Шәхесне раслаучы документлар;

3.3.2. Вәкилнең вәкаләтләрен раслаучы документ (әгәр мөрәҗәгать итүче исеменнән вәкил эш йөртсә);

3.3.3. Участок схемасы Якындагы корылмаларга яисә киселергә тиешле яшел үсентеләр төшерелгән башка ориентирларга кадәр участокның схемасы;

3.3.4. Җир кишәрлеге бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында теркәлмәгән булса, җир кишәрлегенә хокукны билгели торган һәм хокукны раслый торган документларның расланган күчермәләре;

3.3.5. Биналар һәм корылмалар төзегәндә габаритларга эләгә торган яшел үсентеләр киселгән очракта, расланган проект документлары;

3.3.6. Алар территорияләренә кагылган хуҗалар белән яшел үсентеләрне кисү һәм күчереп утырту шартларын килештерү;

3.3.7. Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычның булмавы турында белешмә (мөрәҗәгать итүче инициативасы буенча) авария хәлләренә бәйле очракларда соралмый (бирелми).

3.3.8. Агач утыртканда яки күчереп утыртканда, инженерлык челтәрләре вәкилләре белән җир эшләре башкаруга ордер ачу килештерүе.

Югарыда күрсәтелгән эшләр мөрәҗәгать итүче хисабына башкарыла.

Рөхсәтнең гамәлдә булу вакыты - 30 көн.

3.4. Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре башкарма комитеты мөрәҗәгать итүченең гаризасы нигезендә Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре территориясендә яшел үсентеләрне кисүгә рөхсәт бирү турында күрсәтмә проектын әзерли.

3.5. Яшел утыртмаларны кисүгә гариза бирүче эшләр башкаруга рөхсәт алганда әлеге нигезләмә нигезендә яшел үсентеләрне кискән өчен түләү кертергә яки компенсация рәвешендә яшелләндерүне раслаучы документларны тапшырырга тиеш.

3.6. Агач һәм куакларны кискән өчен түләү гариза бирүче тарафыннан җирлек бюджетына күчерелә.

3.7. Яшел утыртмаларны кисү эшләре билгеләнгән нормалар һәм кагыйдәләр нигезендә гариза бирүче исәбеннән башкарыла. Агачларны кисү аттестацияләнгән белгечләргә генә рөхсәт ителә.

3.8. Егу, кисү, киселгән яшел утыртмаларны һәм кискәннән калган калдыкларны төяп түгү эшләрне башлаганнан соң өч көн эчендә мөрәҗәгать итүче хисабына башкарыла. Эш башкарган урында киселгән агачларны һәм кискәннән калган калдыкларны саклау тыела.

3.9. Кисү урынына якын территориядә газонга, яшел үсентеләргә зыян килгәндә, эш башкаручы аларны территория хуҗасы һәм контрольлек итүче органнар белән аларның компетенциясе чикләрендә килештерелгән срокларда, ләкин зыян килгән вакыттан ярты елдан да соңга калмыйча, мәҗбүри торгыза.

3.10. Түләү кертмичә генә агачларны һәм куакларны кисү башкарма комитет тарафыннан түбәндәге очракларда рөхсәт ителергә мөмкин:

3.10.1. яшел үсентеләрне тәрбияләү, санитар кисүләр һәм реконструкцияләү вакытында;

3.10.2. авария һәм башка гадәттән тыш хәлләр вакытында, шул исәптән җир асты коммуникацияләрен һәм капиталь инженерлык корылмаларын ремонтлаганда;

3.10.3. дәүләт санитар-эпидемиологик күзәтчелек үзәге бәяләмәсе булганда, торак һәм җәмәгать биналарында яктылык режимын боза торган агач һәм куакларны кисү;

3.10.4. һәлакәт китереп чыгару куркынычы булган (ауган, корыган) агачларны һәм куакларны кисү.

3.11. Югарыда күрсәтелгән очракларда яшел үсентеләр кисүне гамәлгә ашыручы мөрәҗәгать итүчегә башкарма комитет белән килештерелгән урыннарда компенсация рәвешендә яшелләндерү үткәрергә кирәк.

3.12. Авария хәлендәге, корыган һәм хәвеф-хәтәр куркынычы тудыра торган яшел үсентеләр комиссия карап тикшергәннән соң киселә.

3.13. РФ Урман кодексының 20 статьясына тәңгәлләштереп, гражданга яисә юридик затка милеккә тапшырганнан соң җир кишәрлегендә хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәсендә яки табигый рәвештә барлыкка килгән агач-куак үсемлекләре хуҗа милке булып санала, ул аннан үзе теләгәнчә файдалана ала.

3.14. Яшел үсентеләрне рөхсәтсез кисү яки юкка чыгару дип түбәндәгеләр таныла:

3.14.1. рөхсәтсез яисә рөхсәт белән, әмма рөхсәттә күрсәтелгән кишәрлектә һәм билгеләнгәнчә санда түгел һәм тиеш булмаган токым агачларны һәм куакларны кисү;

3.14.2. ут төртү яки ут белән саксыз эш итү нәтиҗәсендә агачларны һәм куакларны юк итү яки зыян китерү;

3.14.3. кәүсәне божралау яки төпләү;

3.14.4. үсә торган агачларның һәм куакларның үсешен туктатырлык дәрәҗәдә зыян китерү;

3.14.5. агач һәм куакларны юынтык сулар, химик матдәләр, калдыклар һәм башка шуның ишеләр белән зарарлау;

3.14.6. корыган агачларны рөхсәтсез кисү;

3.14.7. үсә торган агачларга һәм куакларга башка төрле зыян салулар.

3.15. Дәүләт урман фондында исәпләнгән агачларны һәм куакларны кисү махсус вәкаләтле дәүләт органнары тарафыннан бирелгән рөхсәт нигезендә генә гамәлгә ашырыла.

## 4. Компенсация рәвешендә яшелләндерү

4.1. Компенсация рәвешендә яшелләндерү рөхсәт ителгән кисү, яшел утыртмаларга законсыз зыян салу яки юкка чыгару очракларында гамәлгә ашырыла. Компенсация рәвешендә яшелләндерү агачлар, куаклар һәм газоннар утырту өчен яраклы якын сезонда, әмма яшел үсентеләрне зарарлау яки юкка чыгару факты ачыкланганнан соң бер елдан да соңга калмыйча башкарыла.

4.2. Компенсация рәвешендә яшелләндерү агач-куакларга алар мәнфәгатьләрендә яисә аларның хокукка каршы гамәлләре нәтиҗәсендә зыян китергән гражданнарның яисә юридик затларның акчалары исәбеннән башкарыла.

4.3. Әлеге нигезләмә нигезендә яшел утыртмаларга китерелгән зыян табигый формада кайтарылырга – компенсация рәвешендә яшелләндерелергә тиеш: юк ителгән яшел утыртмалар 2 коэффиценты белән яңадан торгызыла.

## 5. Шәһәр төзелеше буенча эшчәнлек башкарганда яшел үсентеләрне (утыртмаларна) саклау

5.1. Районда шәһәр төзелеше эшчәнлеген тормышка ашыру яшел үсентеләрне саклау таләпләрен үтәп алып барыла.

5.2. Яшелләндерелгән территорияләр, шул исәптән яшел массивларда, шулай ук яшелләндерелгән территорияләрне үстерү өчен билгеләнгән җир кишәрлекләрендә аларның максатчан билгеләнешенә бәйле булмаган максатларда файдаланылырга һәм аларда төзелеш эшләре алып барылырга тиеш түгел.

5.3. Яшел үсентеләр биләгән җир кишәрлекләрендә төзелеш эшләрен оештырганда, проект документларында киселергә тиешле яшел утыртмалар турында бәяләмә булырга тиеш. Бу очракларда зыянны каплау әлеге

нигезләмәнең 2 һәм 3 бүлекләрендә билгеләнгән тәртиптә киселгән агач өчен түләүне алдан кертү һәм компенсация рәвешендә яшелләндерү юлы белән гамәлгә ашырыла.

## 6. Эшмәкәрлек алып барганда яшел үсентеләрне (утыртмаларны) саклау

6.1. Яшелләндерелгән территорияләрдә һәм яшел массивларда, сәүдә иткәндә һәм башка эшмәкәрлек белән шөгыльләнгәндә, башкарма комитет рөхсәтеннән башка, палаткалар һәм башка корылмалар урнаштыру тыела.

6.2. Эшмәкәрлек эшчәнлеген тормышка ашырганда, яшел территорияләрдә һәм яшел массивларда шартлау, янгын куркынычы тудыра торган һәм агулы матдәләр куллану, территорияне пычрату һәм чүпләү, яшел үсентеләргә зыян китерердәй яки аларның юкка чыгуына китерердәй башка гамәлләр тыела.

## 7. Җаваплылык

7.1. Әлеге нигезләмәне бозуда гаепле затлар Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә җавап тота.